

Анын сугышчан олы бvләкләре юк. Аерым хөрмәтләv билгеләре, грамоталары, Рәхмәт хатлары бар, ә сугышчаннары - юк. Әмма анын тормышында да Афганистан vз эзен калдырган.      Рашид Вәкил улы Каримов Дубенка районында урнашкан Ломат авылы жирләрен һәм анын белән бәйле булган ботен нәрсәне бик ярата. Ун яшьлек егет әтисе Вәкил белән Ломат колхоз кырларында комбайнчы ярдәмчесе булып эшлләгән инде. Алтын елга булып комбаиннан ашлыкнын машинага коелуын карарга бик тә ошый иде ана.

– Шундый матурлык, хәтта йорәк кысыла! - хәзер дә vзенен балалар хатирәләренә куанып яши Рашид Вәкил улы. - Әти мине һәр жирдә vзе белән ала иде: басуга, гаражга, остаханәләргә. Нәкъ әтием миндә техникага мәхәббәт тәрбияләде.

Авыл мәктәбен тәмамлаганнан сон, Рашид ике уйлап тормыйча,  ДОСААФнын Чамзинка автомәктәбенә укырга керә. Укуны тәмамлауга, 1986 елнын козендә, хәрби комиссариаттан солдатка алыну турында повестка бирәләр.

– Ул вакытта армия хезмәтеннән качып калу дигән уй фикердә дә юк иде – хәрби хезмәт намус эше булды. Хезмәт итеп кайткан егетләргә кызлар да башкача карый иделәр, – ди әнгәмәдәшем. – Бу хәзер ботен гаиләсе белән антка-присягага баралар, акча жибәреп торалар, телефон аша кон саен сойләшәләр. Ә минем әти-әнием хезмәтемнен беренче вакытларын ничек vткәргәнем турында белмәделәр дә…

Армиядә vткән укулардан (учебкадан) сон, 2042 хәрби частенә бvлv башлана. Рәшид Каримовны элемтә ротасында йортvче итеп билгелиләр. Афганистан сугышы башланганда ук Керкинский погранотрядынын резерв мотомангруппасына кертелде ул. Шул вакыт Россия хәрби хезмәткәрләре Туркменстан-Афганистан чиген саклаган. “Техника торле иде, әмма мина ике УАЗ-469 һәм ГАЗ-66 КШМ машиналары беркетелде, - ди ул. - Безнен бурыч - Шиберганда, Мейменда, Анхойда һәм Советлар Союзы чикләренә тоташкан башка Тоньяк торак пунктларда урнашкан Совет мотоманевр торкемнәрен матди-техник ресурслары белән тәэмин итv булды. Мин сугышларда катнашмадым, әмма чынлык кырыс иде: сугыш барды. Еш булмаса да, колонналар атуга да, һожvмгә дә дучар ителде”, - дип хәтерен янарта Рашид Вәкил улы Каримов. Шундый вакытта дуслык олы кадердә була. Үзенен дусты - Оренбургтан хезмәттәше Петр Лагутинны аерым жылылык белән искә ала Рәшид Вәкил улы. Анын белән “Град” системасы очен сугыш кирәк-яраклары салынган автомобиль баранкасын бvлеште.

Сугышчы-интернационалист ике елдан артык легендар 47нче Керкинский погранотрядында хезмәт итvе белән горурлана язма героебыз. Душманнарга каршы корәшкән десант-штурм маневрлар торкеме штабы начальнигы, Советлар Союзы Герое

Н.Н.Лукашовнын батырлыгына соклана. Шулай да Рашид Вәкил улы Афганистан чорын vз биографиясенен героик сәхифәсе дип санамый, тик Афганистан vткән дуслары-кvршеләре Рамиль Куренков белән Альмер Әмиров кебек аларны “вакыт сайлады” дип уйлый: 80нче елларда боерык алган башка йозләгән егет һәм кызлар кебек vк, кайнар ноктага юл алган кеше ул.

Наилә НАСЫРОВА